| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОШУГУРОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ ШӨГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

2023 елның 26 октябре №30

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 5 декабрендәге 16 номерлы карары белән расланган «2023-2024 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» җирләрен файдалану һәм саклау» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 21 июлендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 5 декабрендәге 16 номерлы карары белән расланган «2023-2024 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» җирләрен файдалану һәм саклау» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 бүлекнең 2 абзацында «авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфракның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту өчен» сүзләрен «җирләрнең үзлекләрен яхшырту, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу өчен» сүзләренә алмаштырырга (2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә).

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 1 йорт (җирле үзидарә бинасы); Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 3 йорт (балалар бакчасы бинасы); Иске Шөгер авылы, М.Җәлил урамы, 33 йорт; Яңа Шөгер авылы, Гагарин урамы, 1а, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымлда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова